СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИЖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

27 ноябрь, 1998 ел.
ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 135 (8292) | Бәясе билгеләнгәнчә

***Халыкара инвалидлар көне җитә***

## ЗАМАНА АВЫР ДИП БӘГЫРЬЛӘРНЕ КАТЫРМЫЙК

***Хәбәрчебез сорауларына район хакимиятенең халыкны социаль яклау идарәсе башлыгы Л.Н.ДИЛМӨХӘММӘТОВА җавап бирә.***

***- Лидия Николаевна, быел тагын Халыкара инвалидлар көне билгеләп үтеләчәк. Бу катлау кешеләренә карата мәрхәмәтлелек күрсәтү, аларны кызгану турында күп сүз болгатырга мөмкин, әмма, [illegible]шик, базар шартлары социаль сфераны да бик кырыс кысаларга китереп кысты. Шуңа күрә, әйтегез әле, сезнең күзгә карап диярлек торучы бу кешеләрнең авыр хәлен ничек тә җиңеләйтүтеләге шәһәр һәм районның мөмкинлекләре белән туры киләме соң?***

- Авыр заман хәзер. Шуңа күрә социаль яклау идарәсенең дә принцибы бер - ярдәмне иң мохтаҗларга гына күрсәтергә. Инвалидлар шул төркемгә керә. Районда 336 Бөек Ватан сугышы, 47 Совет Армиясе инвалиды бар, 453 кеше - балачактан гарип, 56сы - эштә имгәнгән, һәм иң күбе - 1322 кеше гомуми авырулардан инвалид калучылар. Шулай булгач, безнең проблемаларның бихисап икәнлеген чамалый торгансыздыр. Тик шулай да без, Республика программасын үти барып (ә ул 1993 елдан гамәлдә), инвалидларга адреслы ярдәм күрсәтеп барырга тырышабыз. Мисал өчен, алар электр, газ, җылылык, фатир өчен, төп категория телефон өчен түләүләрдә 50 процент ташламадан файдаланалар, 1 октябрьдән 15 майга кадәр аларга шәһәрара маршрутларда йөрүдә льготалар бирелә. Билгеле, гомуми социаль хәл үзен сиздерә - бер Нурлат районы гына муллык утравы булып кала алмый һәм без дә пенсияләрне вакытында биреп бара алмыйбыз, Пенсия Фондының район бүлеге җыйган акча һич кенә дә җитәрлек түгел, шулай да шәһәр һәм район хакимияте, аның социаль яклау идарәсе, үз эшләрендә төп игътибарны аеруча мохтаҗларга биреп булса да, социаль яклау программасының төп юнәлешләрен актив төстә гамәлгә ашырырга тырышалар.

***- Ә бу катлаулы икътисадый шартларда инвалидлар ункөнлеге ничек узачак, соңгы елларда ул районыбызда традициягә кергән иде бит инде...***

- Бу чарага без алдан ук әзерлек башладык. Чаралар планы төзелде, хакимият башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев җитәкчелегендә комиссия оештырылды. Бездә инвалидларны хезмәт коллективларында чәй табыны артына җыю, алар өчен концертлар оештыру, бүләкләр, сувенирлар, азык -төлек җыелмалары, кондитер әйберләре өләшү, безнең социаль ярдәм бүлекчәләре көче белән исә, каты авыру инвалидларның йорт - фатирларын җыелчә ремонтлау һәм җыештыру, стационарда дәваланучыларның барып хәлләрен белү гадәткә кергән. Сүз уңаеннан, районга инвалидлар өчен дип "Крутушка", "Васильево" һәм Баулы янындагы "Березка" санаторийларына 20 путевка бирелүен дә әйтергә кирәк. Декабрьнең беренче декадасында район үзәк һәм участок хастаханәләрендә мохтаҗларны чираттан тыш караячаклар, 1- 4 декабрьдә бушлай мунча юынырга һәм чәч алдырырга мөмкин булачак. Мәктәпләрдә тимурчылык хәрәкәте дә яңарыр дип ышанабыз. Инвалидларның ишегалларыннан кар көрәү, утыннарын ярып бирү, тәрәзәләрен ябыштыру, өйләрен җыештыру, мәктәп үзешчәннәре көче белән аларга концерт кую, китапханәдән яңа китап, кибеттән азык - төлек алып кайту, туганнарына, балаларына хатларын язып бирү кебек эшләр укучыларның хәлләреннән килмәслекмени. Бары тик теләк, бераз вакытыңны кызганмау һәм, билгеле инде, күңел изгелеге кирәк. Сүз уңаеннан, безнең райондагы бер генә чарадан да читтә калмаучы "Ветеран" хоры да инвалидлар алдында чыгыш ясарга җыена. Сугыш һәм хезмәт ветераннарын "Чуваш сандугачы" республика конкурсының 25 ноябрьдә район мәдәният йортында булган шәфкатьлелек концертына да чакырдык. ТР Социаль тәэминат министрлыгының "Бөтен дөньяның караңгылыгын каргаганчы, йөрәкләрдә утны тергезик" дигән шәфкатьлелек акциясендә дә катнашабыз. Акциянең исемендә символик мәгънә бар, сизәсездер. Сүз инвалидлар ясаган кул эшләрен аукционда сатып, аннан кергән акчаны адреслы төстә конкрет гаиләләргә, аерым кешеләргә ярдәм итүгә тоту турында бара.

***- Лидия Николаевна, ә газетабызның алдагы санында хәбәр ителгән "Алтын йөрәк" акциясе ничек бара районда?***

- Сүз дә юк, социаль яклау системасы камиллектән ерак әле, ул зур матди чыгымнар сорый, шуңа күрә дә без хәлле кешеләрнең юксылларга булышлык итәргә теләүләренә һәм ризалашуларына һәрвакыт бик шат булабыз. Шәфкатьлелек ашлары оештыру да кирә монда (алары ешрак булса яхшы да бит), тотылган өс - баш җыю, матди ярдәм күрсәтү дә. Әйтик, шундый акча кытлыгы булуга да карамастан, НГДУның УТТ коллективы (И.Г.Вәлиуллин) әтисез генә түгел, әнисез дә калган гаиләгә ярдәм күрсәтү мөмкинлеге тапты. Башка хезмәт коллективлары, эшмәкәрләр, аерым затлар да декада барышында безнең

**40205810300000170031**
**БИК 049241000 ИНН**
**1632002325**

счетына акча күчерсәләр ничек шат булыр идек без. Ышанычыз, алар беренче чиратта иң мохтаҗларга биреләчәк. Беренче взнослар бар да инде.

***Шулай итеп, инвалидлар ункөнлеге 1 декабрьдә старт ала. Ул декада төссез генә, формаль төстә үтмәс, ә активлык белән һәм мөмкин кадәр нәтиҗәле булып узар дип ышанасы килә. Болай да кыерсытылган кешеләр бу көннәрдә генә булса да игътибар һәм кайгыртуны ныграк тойсыннар иде.***

*Т.НАЗАРОВА сөйләште.*

## АЛТЫНГА ТИҢ БАЙЛЫК АЯК АСТЫНДА ЯТМАСЫН

Соңгы бер - ике елда районга минераль ашлама бик күп кайтты һәм аның барысы да диярлек кырларга кертелде. Былтыр рекордлы уңыш алуыбыз да күп яктан нәкъ менә шуның нәтиҗәсе булды, узган ел көздән кертеп калдырмаган һәм иртә язда тамырдан туклandыру уздырмаган булсак, уңышның быелгысы да күпкә түбәнрәк буласы иде. Шулай булгач, минераль ашламаларны куллану киләчәктә дә игътибар үзәгендә булырга тиешле чара. Ә инде ашлама көткән нәтиҗәне бирсен өчен аның үзенә дә зур игътибар булу шарт. Бу очракта сүз беренче чиратта минераль ашламаларны ышанычлы саклау, бәрәкәтле тоту турында бара. Шуңа күрә дә шушы арада гына һәр хуҗалыкта булып, минераль сыйның ничек саклanышы тикшереп чыгылды.

Шунысы игътибарга лаек, игенчелек культурасы чын мәгънәсендә югары, шуңа күрә уңыш та чагыштырмача ишле булган хуҗалыкларда минераль ашламаларга хәзер дә җитәрлек игътибар бирелә. "Өмет" агрофирмасында, Хафизов исемендәге, Синдряков исемендәге, "Рассвет" һәм кайбер башка хуҗалыкларда минераль ашламаларның сакланышы да яхшы, аларны исәпкә алу мәсьәләсендә дә ныклы тәртип. "Таң", РСУ, шикәр заводы ярдәмче хуҗалыкларында да минераль ашламаларның сакланышына сүз әйтеп булмый. Аларда барлык ашлама да түбә астында, кар - яңгыр үтәрлек түгел, капчыклылары аслыкларга таслап өелгән, капчыксызлары да таралып ятмый. Ул җәһәттән "Чирмешән" агрофирмасының Салдакай бүлекчәсендәге складтагы тәртип игътибарга лаек. Әйтүләренә караганда, берара күз уңыннан ычкынып торган ул складны тәртипкә китерү өчен, булган ашламаны башта бер урынга ташып, складны чистартып чыгарырга һәм 315 тонна ашлама капчыкларын яңадан рәтләп урнаштырырга да иренмәгәннәр. Яңа җитәкчелекнең эшкә чын хуҗаларча каравына бик җитди мисал бу. Инде хуҗалыкның "Үрнәк" КХАсы белән уртак складында да шундый тәртип урнаштыра алсалар, бик тә яхшы буласы, югыйсә биредә озак еллардан бирле килгән хуҗасызлыкның нәтиҗәсе күзгә ташланып тора әле. Аннары инде язын ашламаны аяк астыннан эзләргә туры килмәячәк.

"Татарстан", "Алга", "Төрнәс" һәм кайбер башка хуҗалыкларда да минераль ашламалар яхшылап өеп куелган. Әмма ашламага караш һәркайда да болай түгел әле. Ашлыктан кыйммәт байлыкка, әй, ашлама гына бит ул, дип караучылар да бар. Моңа кадәр ул яктан "Игенче"дә хәл бик аяныч иде. Дөрес, җитди тәнкыйтьтән соң ашлама складларында тәртип урнаштырылды, әмма капчыкларда кайткан ашлама хәзер капчыксызга әйләнеп калды. Кайткан ашламаны вакытында өеп куеп, складны бикләп алмауның нәтиҗәсе менә ничек бит ул. "Комбайн"ның бер складындагы күпмедер ашламаның язмышы да аяныч хәлдә - ул таралып ята, складның ишеге бик начар. Ул җәһәттән, складларында ашламалар таслап урнаштырылган хуҗалыкларның да кайберләрендә, аерым алганда шикәр заводы ярдәмче хуҗалыгында, "Рассвет"ның Якты Күл, "Кондырча"ның Югары Нурлат бүлекчәләрендә складларга мөдир билгеләнмәгән. Бу исә ашламаның төгәл исәбен алып бару мәсьәләсендә дә тәртип юк дигән сүз. Кайбер хуҗалыкларда ни кайткан, ни киткән ашламага җентекле учет алып барылмый: накладнойлардагы саннарны теркәп куялар да, шуның белән эш бетә. Кайберләрендә бухгалтерлар складтан күпме ашлама киткәнен, "Игенче"дәге кебек, бер агроном сүзеннән чыгып кына язып баралар. Ә моның ахыры ничек булып бетүенә районда бик гыйбрәтле мисаллар бар бит инде, югыйсә. Шикәр заводы ярдәмче хуҗалыгында, "Кондырча"да һәм кайбер башка хуҗалыкларда ашламаның күпмесе кайсы кырга кертелгәнлеге теркәп барылмый, махсус журналлар тотылмый.

Кыскасы, алтын бәясенә төшә торган минераль ашламага моннан ары һәркайда да җитди караш, минераль сый килограммына кадәр исәптә булырга тиеш. Һәм ашлама турында чәчүгә чыккач кына түгел, ә ел буе кайгыртырга кирәк. Шуңа күрә без дә бу темага тагын әйләнеп кайтачакбыз әле.

**В.ГАВРИЛОВ,**
**авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсенең үсемлекчелек бүлеге башлыгы.**

**Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ,**
**безнең хәбәрче.**



***Владимир Арсентьевич Алексеев "Лениногорск тампонаж эшләре идарәсе" чикләнгән җаваплылыктагы җәмгыятенең Нурлат филиалында 2 еллап кына эшли әле. Әмма техник яктан грамоталы, гаҗәеп төгәл һәм тәртипле шофер булдыклы коллективта үзе турында уңай фикер уятырга өлгерде инде. Ул - цемент ташу машинасы шоферы. Үзләре өчен иң мөһим булган бу материалны ул башта Лениногорск, Жигулевск кебек шәһәрләрдән ташый, аннан буровойларга илтә. Шулай итеп, аңа ерак чакрымнарны да урарга, кыен буровой юлларын да бертигез җаваплылык белән узарга туры килә. Әле соңгысы аның заказчы сәгатеннән чыгып тәүлекнең теләсә кайсы вакытында булуы ихтимал. Владимир Арсентьевич һәрчак эшенә җаваплы карый, өзеклекләргә юл куймый.***

*Рәсемдә: В.А.Алексеев.*
*Н.АЗИЗОВ фотосы.*

***Рәсми хроника***

## ЯҢА РӘИС

24 ноябрь көнне "Комбайн" КХАсы әгъзаларының гомуми җыелышы булды. Анда оештыру мәсьәләсе каралды. Җыелыш, башка эшкә күчүе сәбәпле, хуҗалык рәисе Д.В. Фәссахovны вазифаларыннан азат итте. Хуҗалык рәисе итеп шул ук хуҗалыкта рәис урынбасары булып эшләгән *Рәшит Әһлиулла улы ИБӘТУЛЛИН* сайланды.

**«ДУСЛЫК»КА ЯЗЫЛУ БАРА**

***1999 елның беренче яртысы өчен "Дуслык" ("Дружба", "Туслах") район газетасына язылу бәясе - 25 сум 20 тиен. Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәм инвалидларга, Әфган сугышында булучыларга, Чернобыль атом электр станциясендәге фаҗига нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучыларга тиешле документлар нигезендә 50 процент ташлама ясала.***

# ШӘҺӘРГӘ СУНЫ КЕМ БИРӘ?

***Кеше уңайлыкка тиз күнә. Әле ел ярым элек кенә чиста суны сәгатьләп көтеп алсак, хәзер су өзеклеге килеп туса, гадәттән тыш хәл кебек тузына башлыйбыз. Узган якшәмбе көнне ярты көн сусыз краннарыбызны боргаладык. “Дала Мамыгында төзексезлек килеп чыкты, тиздән су биреләчәк”,- дип тынычландырырга ашыктылар безне.***

***Ә безгә калса, шулкадәр зарыгып көтеп алган артезиан суы бирүдә өзеклек һич булырга тиеш түгел төсле иде. Әмма һәр хезмәтнең үз үзенчәлеге шул.***

Сүз Дала Мамыгындагы сукүтәрткеч турында бара. Узган елның 24 июленнән бирле биредә тормыш кайный. Зур булмаган хуҗалык гаять мөһим эш башкара: шәһәрне артезиан суы белән тәэмин итеп тора.

Су күтәрткече мастеры Галиулла Нәбиуллович Бикташев борчылырга урын булмавын ышандырырлык итеп аңлатты. Ул - бу хуҗалыкның иң төп хуҗасы икән. Аннан кала сигез насос җайланмасы машинисты, ике скважиналарны карап торучы (обходчик), бер слесарь һәм дүрт каравылчы эшлиләр. Эш тәүлек әйләнәсенә - 4 сменада оештырылган. Службаның максаты - 5 скважинадан суны суыртып, шәһәрне өзлексез артезиан суы белән тәэмин итеп тору. Бишесе биш җирдә урнашкан скважиналардан су торба аша сукүтәрткеч хуҗалыкның беренче баскычы булган җыю блогына керә, аннан 200әр куб метрлы ике сыешлыкка, аннан насос блогына күчә һәм шуннан куәтле басым астында трассага кудырылып, шәһәргә юл ала.

- Тәүлегенә 2 мең куб. метрга кадәр су бирәбез шәһәргә,- диләр насос җайланмасы машинистлары Й.И.Җәббаров белән С.Г.Тимербулатов. Алар - бу хуҗалыкта иң төп профессия кешеләре. Скважиналарда андый - мондый төзексезлек килеп чыкса, анысын обходчиклар кайгырта, үз көчләре белән генә төзәтерлек булмаса, рация аша МППның үзәк авария службасы белән элемтәгә керәләр. Һәр төркем үз сменасында эшнең ничек барышын журналга терки бара, төзексезлек сәбәбен дә, су өзеклеге вакытын да тиз белергә була.

-Алдагы шимбәме? Бер скважинада насосны алыштырдык. Нишлисең - һәрнәрсә туза бит. Быел гына да өченче насосны яңартырга туры килде.

- Ә бу якшәмбе көнне су дәрәҗәсен күрсәтә торган күрсәткеч туңды, көн суык иде бит. Андый хәлләрне булдырмаска тырышабыз да бит...







***Рәсемнәрдә: обходчик Ә.Н.Рәхмәтуллин; машинист С.Г.Тимербулатов; машинист Й.И.Җәббаров эш урынында; сукүтәрткеч территориясе.***

Су хуҗаларының сәбәбе акланырлык кына түгел, җитди сәбәп булуын аңласак та, сусыз еллар (ә хатын - кыз бөтен эшен нәкъ шул көннәргә калдыра бит!), суга тилмергән сәгатьләр булмасын иде инде ул!

Ул нияттән дә эш бара икән. Әлмәт геологик эзләнү экспедициясе янә 3 скважина бораулаган, будка куеп насос төшерәсе генә калган. Анысы да башкарылгач, шәһәргә бирә торган су күләмен 3 мең куб. метрга җиткерү мөмкинлеге булачак икән. Аварияләр кайчак шәһәр эчендәге торбалар искелегеннән дә килеп чыкканлыктан, шәһәрдәге “Огонек” кибетеннән чистарту корылмаларына кадәрге 2 км. арага яңа полиэтилен торба сузылган, озакламый аны төп трасса, йортлар белән ялгарга җыеналар. Кайчак су бирүчеләр электр уты белән килеп чыккан өзеклек сәбәпле эшләрен тукталып торырга мәҗбүр булалар икән. Мондый хәлдән чыгу өчен үзләрендә дизель станциясе куюны тәгаллләп киләләр.

Әнә шулай шәһәрне артезиан суы белән тәэмин итү көннән - көн ышанычлырак рәвеш ала бара. Нурлатлылар кранны борган саен, аны гамәлгә ашыручы район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллинга рәхмәт укыйлар. Инде суны тиешле басым белән кирәкле күләмдә өзеклексез биреп торсалар, МППның сукүтәрткеч участогында эшләүчеләр дә изге теләкләргә тилмермәсләр, дип уйлыйбыз.

**С.НУРУЛЛИНА.**
**Н.АЗИЗОВ фотолары.**

***“Нурлатнефть” НГДУсында***

# ЕРАК ПРОМЫСЕЛДА ОЧРАШУ

Идарәдә 74 кеше мастер булып эшли. Идарә җитәкчелеге нәкъ менә шушы урта буын командирларына зур өмет баглый. Шуңа да алар белән эшнең беренче планда торуы гаҗәп түгел. Бу өлкәдә инде шактый тәҗрибә бар. Мастерларның киңәшмәләрен, бригадалар арасында һөнәри осталык конкурслары үткәрү гадәткә керде. Ә ул конкурсларда бригаданың уңышлы чыгыш ясавы күпъяклап нәкъ менә мастерга бәйле. Идарә күләмендә “Ел мастеры” конкурслары үткәрүне алыйк тагын. Быел ул исемгә өч кеше лаек булды, биш кеше “Татнефть” АҖ һәм НГДУның мактау кәгазьләре белән бүләкләнде.

Болардан тыш безнең идарәдә бригадаларның бер - берсенә барып, турыдан - туры эш урыннарында хезмәтнең ничек оештырылуы белән танышулары да уңышлы бер форма булып тора.

... Әнә шулай, ноябрьнең бер көнендә идарәнең барлык нефть һәм газ чыгару мастерлары да икенче промыселга җыелдылар. Шунда ук идарәнең җитәкче хезмәткәрләре, бүлек, служба башлыклары һәм белгечләре дә килде.

Бу промысел - идарә үзәгеннән дә, төп җитештерү һәм тәэминат базаларыннан да иң еракта урнашканы, әмма игътибар мәсьәләсендә һич тә үги күрелми. Җитмеш чакрым ара узып бирегә көн саен күптөрле белгечлек ияләре җыела. Икенче ЦДНГ территориясендә тагын бер - эре басым станциясе - 4нче ДНС һәм үзенең “кан тамырлары” аша елына ике миллион тоннадан күбрәк нефть үткәрә торган әзерләү установкасы да урнашкан.

Бирегә җыелуның максаты промыселда хезмәтнең ничек оештырылуы, андагы эш шартлары һәм җитештерү культурасы белән танышу иде. Ә монда игътибарга алырлык нәрсәләр байтак. Нефтьне җыйнау һәм кудыруның тулы комплексын үз эченә алган 312нче газ үлчәгеч корылма, мәсәлән, - иң иске объектларның берсе. Быел ул тулысынча реконструкцияләнде, искергән җиһазлары алыштырылды, хезмәт шартлары да тамырдан үзгәрде. Бер үк вакытта, көнкүреш шартлары да - быел заманча дәрәҗәдә җиһазлап оператор йорты сафка бирелде. Эш һәм ял өчен иркен, якты бүлмәләре булган бу йортта заманча кухня җиһазлары белән тәэмин ителгән һәм ашау өчен аерым бүлмәле ашханә дә урнашкан.

Ул көнне кунаклар дистәләрчә скважина торышын карадылар, тагын берничә газ үлчәү җайланмасы белән таныштылар. Делегация цехның берничә объектында да булды. Шуннан соң барлык күргәннәр турында 2нче ЦДНГның административ бинасындагы кызыл почмакта зур сөйләшү узды. Анда цех һәм бүлек начальниклары Валерий Воронцов, Илшат Мәннапов, баш энергетик Рәфыйк Мәхмүтов, куркынычсызлык техникасы баш инженеры вазифаларын башкаручы Фәрит Альков “Татнефть” АҖ һәм НГДУның эшчәнлеге турында сөйләделәр, күтәмәләләр эшенә анализ ясадылар.

“Нурлатнефть” идарәсе карамагындагы башка чыганаклар кебек үк, бу чыганак та үз хәзинәсен бик авырлык белән генә бирә. Нефть гаять тә үзле, анда сумалалар, асфальтен һәм күкерт күп. Аннары, озак еллар эшкәртү нәтиҗәсендә - 1974нче елдан бирле моннан булган запасның 44 - 48 проценты алынган инде - катламнарның сулану дәрәҗәсе дә 45 процентка кадәр җитә.

Цех коллективы үзенең төп бурычын үтәү - нефть чыгару буенча зур эш башкара. Уртак тырышлык белән скважиналарның продукция бирергә сәләтле барлык фонды да эшкә җигелгән. Скважиналарның режимын оптимальләштерүгә ирешәләр, геологик - техник чаралар да гамәлгә ашырыла. Ивашкино - Кече Сөлчә чыганагында тегелгән полимер системаларны кудыруның алдынгы технологиясе һәм катламнарга суны цикллап кудыру кертелгән. Шул ук вакытта цех скважиналарны ремонттан соң тизрәк худка җибәрү һәм аларны үзләштерү буенча геологик - техник чаралар мәсьәләсендә оперативрак булырга кирәк әле. Бер үк вакытта җитәкчеләр, белгечләр һәм мастерларга карата хәвефсезлек техникасы, хезмәтне саклау кагыйдәләрен үтәү җәһәтеннән җитди кисәтүләр дә булды. Цех башлыклары Назыйм Шәфыйков, Анатолий Саватников һәм Флорид Садретдинов та күп кенә тәкъдимнәр һәм киңәшләр әйттеләр.

Кыскасы, 2нче ЦДНГ начальнигы Җәлил Мөхәммәтшинга һәм аның кул астындагы мастерларга бу көнне сүзнең яхшысын да, тәнкыйть характерындагысын да шактый ишетергә туры килде.

Киңәшмәгә йомгакны идарә начальнигының кадрлар һәм юридик мәсьәләләр буенча урынбасары Дамир Вәлиев ясады.

“Мондый очрашулар мөһим һәм файдалы. Формаль булмаган аралашу, фикер алышу - бик яхшы мәктәп ул. Без, мастерларга да күп нәрсә бәйле икәнлегенә тагын бер тапкыр инандык. Кайчагында моны үзебез дә ахыргача аңлап бетермибез без. Ә кирәк”, - икенче бер цех мастеры Евгений Сидоровның бу сүзләре башка коллегаларның фикере дә дип уйларга туры нигез бар.

**В.БУРАЙКИН.**

# ХӘДИЧӘ ӘБИ РӘХМӘТ ӘЙТӘ

Дөнья шулай корылган инде ул. Кеше үз гомерендә сабый баладан олыгайган кешегә әверелә. Җырда җырланганча:

Гомерләр үтә икән ул,
Үтә дә китә икән...

Әйе, гомерләр үтә икән шул. Заманында җир җимертеп эшләп йөргән Хәдичә әби дә сигезенче дистәневаклый инде. Ләкин ул ялгыз түгел. Аның үз әниләредәй якын күреп, хәлен белеп, һәр эшендә даими булышып торучы күршеләре бар. Әле менә бер күзе күрми башлагач, авылыбыз шәфкать туташы Гөлсинә Гәрәева аны районның күз врачына алып барып операция ясатты. Операция уңышлы чыкты, әбинең күзе күрә башлады. Хәдичә әби газета аша районның күз врачы Мидхәт Галиевка, шәфкать туташы Гөлсинә Гәрәевага һәм күршеләре Зөлфа Шәһивәлиевага, Суфия Гафиятуллинага, Тәскирә Хәмәтвәлиевага, Сәвия Хәйдәровага, Зөлфия Дәүләтшинага, Сара Нургалиевага һ.б.га зур рәхмәтләрен юллый, аларга исәнлек - саулык, озын гомер тели.

**З.ИСМӘГЫЙЛЕВА.**
**Кычытканлы авылы.**

***Һәммәбез дә бу фани дөньяда яшәү белән үлем арасындагы гомер юлыннан барабыз. Әмма безнең реанимация бүлегенә гозере төшкәннәрнең язмышы, гадәттә, кыл өстендә була. Монда гади генә игътибарсызлык та кеше гомеренә бәрабәр булырга мөмкин. Яки, киресенчә, авыруның аңына килеп күзен ачуына әйтелгән бер җылы сүз, кайгыртучан караш аңа бөтен дарулардан да өстенрәк сихәтләнү көче бирергә сәләтле бит. Шуңа күрә дә бу бүлектә эшләүчеләр өчен хезмәтеңдә игътибарлы булу, төгәллек һәм сабырлык - язылмаган законнарның иң мөһиме.***

## *"Алтын йөрәкле ир" конкурсына кандидат*

***Доктор, доктор! Синең йөрәккәең***
***Алтын бәһасенә торырлык!***
***Шундый олы җанлы остаз белән***
***Эшләвең дә нинди горурлык!***

# ИДЕАЛЬ КЕШЕ БУЛМЫЙ, ДИЛӘР...





Бүгенге көндә реанимация бүлегендә 5 табиб, 14 шәфкать туташы, 4 санитар һәм 4 лаборант эшли. Көннең төн белән яки киресенчә алышынганлыгын сменасы узуга карап кына тоемлаучы коллектив өчен бер дә күп димәс идек без моны. Чөнки бу бүлекнең хезмәтендә көн белән төннең аермасы юк. Хәер, кичен һәм төнлә авыруларның физик хәләте тынгысызрак булуын, сырхауның ныграк бимазалавын искә алсаң, тәүлекнең сәламәт кешеләр өчен ял булып хезмәт иткән чоры монда киеренкерәк, борчулырак та үтә әле. Шуңа күрә дә бүлек коллективының теләсә кайсы мизгелдә дә, хәрбиләр теле белән әйтсәк, "сугышчан әзерлек" хәлендә булуы кирәк. Ә инде өч дистәгә якын кешедән торган коллективны шушы халәттә яшәтү, дистә еллар дәвамында аның бөтенлеген саклау, һәрбер әгъзасының мең мәшәкатьләр белән балалар үстерүче әти - әни, үз тормышына да хокукы булган шәхес икәнлеген истә тоту, шуның белән исәпләшә белү өчен акыллы, кешелекле, олы йөрәкле хуҗа кирәклеген танымый мөмкин түгел.

Бар ул андый хуҗа! Әнә ул операциядән соң наркоздан айнып килүче авыру янына килгән... Ә үзәк хастаханәдә күптәннән эшләүчеләрнең байтагы аның яшь белгеч буларак, беренче тапкыр монда эшкә кайтуын хәтерлиләр әле.

1978 елның җәендә кайта Васыйл Габбасович бу коллективка. Ачык көләч йөзле, шуклыгы күзгә бәрелеп торган кара күзле яшь ирне поликлиниканың кабул итү бүлмәсенә хирург итеп билгелиләр. Эшкә керешүенең беренче елында ук ул үзенең игътибарлы булуы, эшкә җаваплылыгы белән хезмәттәшләренең дә, сырхауларның да ихтирамын казана. Аның бу якларын хастаханә җитәкчелеге дә күреп ала һәм яшь белгечне стационарга хирург итеп күчерәләр. Монда инде ул бөтен яклап ачыла. Дару белән генә түгел, сүзе белән дә җан дәвасы бирә торган докторны авырулар түземсезлек белән көтеп алалар, һәр сүзен йотлыгып тыңлыйлар, шаяртуларыннан онытылып көләләр, ә иң мөһиме - терелүгә өметләрен ныгыталар. Хезмәттәшләре белән дә уртак телне тиз таба ул. Һәрвакыт эзләнә, укый, яңалыкларын башкалар белән дә уртаклашырга ярата. Ә инде 1982 елда реаниматолог - анестезиолог белгечлеге буенча укырга барырга кеше кирәк булгач, хастаханә җитәкчелегенең дә, хезмәттәшләренең дә тәкъдиме бер була: монда, һичшиксез, өметле яшь хирург Васыйл Габбас улы Әбделмәновны җибәрергә кирәк, диләр.

Укып кайтканнан соң, белемен һәм тырышлыгын җигеп янә эшкә керешә ул. Хирургның эше никадәр авыр булса да, аның "сугыш кыры" бөтенләе белән күз алдында. Ә менә анестезиолог белән авыру арасындагы бәйләнеш күзгә күренми торган халәт бит ул. (Бу урында, сүздән читкә китеп булса да, бер фаразга игътибар итәсе килә: Васыйл дигән исем - гарәп сүзе һәм ул - тоташтыручы, элемтә тотучы, аерылмас дус дигән мәгънәләрне аңлата икән. Ата - ана кушкан исемнең дә кешенең тормыш багланышына тәэсир итүенә мисал түгелме икән бу очрак?) Операция өстәлендә ятучының кан басымы, пульсы, сулыш алу мөмкинлекләре - барысы да аның авыртуны сизү - сизмәвенә бәйле бит. Менә шулай итеп, яшәү белән үлем арасындагы көрәшне бөтен нечкәлекләрен тоеп, авыру белән бергә Васыйл Габбасович та үз җилкәсендә татый...

Нинди генә катлаулы хәлләрдә дә үзенең сабыр акылын саклап калучы, беркайчан да кулларының калтыравын күрсәтмәүче доктор үлем очракларын аеручa тетрәнү белән кичерә.

Район үзәк хастаханәсе зурая төшкәч, иң авыр хәлдәге авырулар өчен аерым урын кирәклеге зур ихтыяҗ булып алга килеп баса. 1982 елның ахырында җитәкчелек реанимация бүлеге ачарга карар бирә. Ә бүлек мөдирен инде эзләргә дә кирәк түгел - кандидатура бер генә. Менә шулай итеп, ул яңа бүлеккә җитәкчелек итә башлый. Үз кул астына шәфкать туташларын да үзе сайлый. Беренче мәлдә монда 5 кешедән торган коллектив оеша. Соңрак коллектив, әлбәттә, үсә. Эш гадәттән тыш җаваплы, авыр булуга карамастан, монда кадрлар алышыну юк дәрәҗәсендә. Хәтта мондагыдан бераз тынычрак урынга китәргә мөмкинлекләр туганда да, берсенең дә моннан китәргә теләге булмады. Чөнки кая гына барсалар да, нинди генә җирдә эшләсәләр дә, кызлар шушындый кешелекле, җаваплы, аларның проблемаларын үзенеке итеп кабул иткән, вакытында тиешле киңәшен әйткән, ярдәм кулын сузган мөдирне башка беркайда да тапмаячакларын бик яхшы аңлыйлар.

Васыйл Габбасовичка быел июнь аенда 45 яшь тулды. Хезмәтендә генә түгел, шәхси тормышында да аның шундый асыл кеше булуы сокландыра. Әти - әнисе өчен аның һәрвакыт тетрәп торуын да беләбез. Өлкәннәрнең исә картлык көннәрендә яшәү урыны итеп уллары Васыйл гаиләсен сайлавы да шуның бер дәлиле, ләбаса. Гаиләдә өч бала үсә. Ачык йөзле, мөлаем һәм тыйнак, уңган хатыны Һәдия белән алар шушы ишле гаиләне бер дә авырсынмыйча, җил - яңгыр тидермичә тәрбиялиләр. Балалар дигәннән, Алмаз белән Лилиясе шәһәрнең 1нче мәктәбен алтын медальгә генә тәмамлап, хәзер югары уку йортында белем алалар. Ә төпчекләре Алия - бу гаиләнең бөтен яхшы сыйфатларын үзенә туплаган алтын бөртеге мәктәбендә абый - апасының йөз аклыгын саклап, тырышып укып йөри.

Габбас бабай улының киң күңелле, һәрвакыт ярдәмчел булуын авылдашлары да беләләр. Аны белеме һәм дәрәҗәсе белән масаймавы өчен яраталар. Шуңа күрә олысы да, кечесе дә аны борчуларын һәм серләрен уртаклашырдай кеше итеп саныйлар, аңа киңәшкә һәм ярдәм сорап киләләр һәм олы ярату, чын горурлык белән: "Безнең Васыйл",- дип йөртәләр.

Тормышта: "Идеаль кеше булмый",- дигән караш яши. Әмма безнең арада шундый кеше бар. Чынлап әйтәбез - бар, тик күз генә тидермәгез.

**Хезмәттәшләре исеменнән**
**А.ЗАРИПОВА,**
**район үзәк хастаханәсенең реанимация бүлеге өлкән шәфкать туташы.**
**Н.БУЛАТОВА,**
**хирургия бүлеге өлкән шәфкать туташы.**
**Н.АЗИЗОВ фотолары.**

***Урлашуларны кисәтү һәм караклыкка каршы көрәш хокук саклау органнарының да, предприятиеләр һәм оешмалар администрацияләренең дә мөһим бурычларыннан берсе булып тора. Урлаучылар административ һәм җинаять җаваплылыгына тартыла яки аларга, китерелгән зыянны түләтеп, җәмәгатьчелек йогынтысына тарту чаралары кулланыла.***

# УРЛАШУЛАРГА КИРТӘ КУЕЛСЫН

Урланган әйбернең хакы хезмәткә түләүнең минималь суммасыннан артмаса, бу вак урлашу санала. Андыйларга карата материаллар, административ яки җинаять җаваплылыгына тарту өчен, судка җибәрелә. Җәмәгатьчелек йогынтысына тартырга кирәк булганда, материаллар теге яки бу җәмәгать оешмасына тапшырыла.

Урлашуларны профилактикалау һәм булдырмый калу күп кенә очракларда предприятие яки оешма җитәкчелеге һәм җәмәгатьчелекнең моңа ничек каравына да бәйле. Кызганычка каршы, гаепләләргә карата һәрвакытта да дисциплинар йогынты ясау чаралары кулланылмый. Мисал өчен, быелның 9 аенда "Төрнәс" хуҗалыгында урлашкан өчен 15 кеше тоткарланды, әмма күрелгән чаралар турында бер генә җавап алынды. Хафизов исемендәге хуҗалыкта җиде урлашуның берсенә карата да җавап юк. "Сөлчә"дә 16 каракның дүртесенә карата гына чара күрелде. "Чирмешән"дә тотылган 9 кешенең берсенә карата да җавап алганыбыз юк. Ит комбинатында тотылган 19, сөт - май комбинатында эләккән 4 кешегә карата да нинди чара күрелгәнлеген белмибез.

Урлаучыларга карата көрәштә катнашу - предприятиеләр администрацияләренең функциональ бурычы. Материаль җаваплы урыннарга кешеләрне дөрес сайлап куярга, ныклы һәм тулы финанс -хуҗалык исәбе булдырырга кирәк, ул чакта кибетләрдә ит тә, сөт тә гел булып торыр.

Ә администрацияләр урлауларга каршы көрәшкә катнашырга теләмиләр икән, бу бары тик милициянең эшен генә кыенлаштыра. Шуңа да андый предприятиеләрне без аерым игътибар үзәгендә тотабыз, тикшерүләрне дә ешрак үткәрәбез.

**А.ЛОГИНОВ,**
**ведомстводан тыш сак бүлегенең өлкән инспекторы.**



***Таныш булыгыз: "Нурлатгаз" эксплуатация - җитештерү идарәсе эшчеләре Ирек Гәрәевич Галиев һәм Владимир Григорьевич Мандрейкин. Аларның һәр икесе - газ җиһазларын ремонтлау буенча комплекслы служба слесарьлары. Бу эшчеләр кулы белән районда ничәмә - ничә йортка табигый газ бирелде. Аларга Кычытканлы, Сәләнгеш кебек ерак авыллар өйләрендә дә зәңгәр ут кабызырга туры килде. Мондый очракта халыкның рәхмәтен, сөенечен күреп, егетләр үзләренең никадәр игелекле эш башкаруларына тагын бер кат инаналар, шуңа да үз вазифаларын җиренә җиткереп үтәргә тырышалар.***

***Фотохәбәрчебез Н.АЗИЗОВ аларны Кычытканлы авылында табигый газ биргәндә төшереп алган иде.***

## Укы да уйла!

# Иссез һәм төссез ҮЛЕМ

### Чукотка рудникларында яшерен медицина эзләнүләре алып барылган

Пермь скульпторы Рудольф Веденеев Чукоткадагы Певек портыннан 70 чакрым ераклыкта урнашкан иске уран рудникларыннан сенсация буларак кабул ителерлек фотосурәтләр һәм шаккатыргыч мәгълүматлар алып кайткан. Ул рудниклар инде күптән ябылган. Әмма алар гөрләп эшләп торган чакта ничегрәк булды икән?

Скульптор анда тупас итеп ташка уеп ясалган гранит баракларны күргән. Бараклар артында ук - зират... Анда табутлар юк. Алар урынына ташка уеп ясалган чокырлар. Алар өстенә ашык - пошык ташлар салынган. Рудольф кинәт имәнеп китә: кабер чокырыннан баш сөяге күренеп тора. Ул гадәттәгечә түгел: баш сөяге маңгай өстеннән ике бармак калынлыгы кисеп алынган, өстәрәк түгәрәк түбәтәй шикелле баш түбәсе капкачы аерылып тора. Тирә - якка җентекләбрәк караса, кабер уемнарыннан аңа шундый ук игез баш сөякләре карап тора. Алар котып җилләрендә кипкән. Тик бер генә дә маңгае киселмәгән баш сөяге юк!..

Ник алай соң әле? Әллә соң бу уран рудникларында эшләгән кешеләрнең баш сөякләрен, үлгәч, кисеп, баш миләрен тикшергәннәрме икән? Шуңа охшый...

Бу тирәләрдә яшәүчеләр сөйләве буенча, 1940 - 50 елларда бирдәге лагерьларда 150 меңнән артык сәяси тоткын уран рудникларында эшләгән. Аунап яткан баш сөякләрен, бәлки, исәпләп тә чыгарып булмыйдыр. Әмма ышанып әйтергә була: Хиросима һәм Нагасаки фаҗигасенә, Семипалатинск һәм Чиләбе гарасатларына кадәр үк, Уралдагы уран рудникларында нурланыш афәтенә юлыккан кешеләрнең баш миләре галимнәр тарафыннан фәнни тикшеренү үткән!

Рудольфның кесәләре аклы - сарылы вак ташлар белән тулы булмаса, ул рәссам дип тә атала алмас иде. Ул аларны өч атна үз кесәсендә йөртте, Пермьгә алып кайтып коллегаларына күрсәтәсе килә иде. Кайткач, ул аларны чынлап та иптәшләренә күрсәтә. Алар әйтәләр, юләр булма, бу ташларны кесәңдә саклау куркыныч, син аларны дошманнарыңа бүләк ит һәм штормовкаңны утка як, диләр...

Айлар, еллар буе көн саен уран рудныгына төшеп эшләгән тоткыннарны күз алдына китерегез әле. Күпмегә чыдар икән ул? Мәгълүматлы кешеләр Веденеевка әйтәләр: ни сөйлисең, нинди еллар, ди, бер ай рудникта эшләү кешене үлемгә китерә!.. Димәк, ай саен уран рудникларына яңа партия тоткыннар китерелә, үлгәч, аларның миләрендә лаборантлар казына... Калса, алардан нибары "бирка" гына торып кала. Бирка дигәннән, "Восточный" шахтасында Веденеев берничә кәгазь бирка табып ала. Димәк, биркасы табылган шахтер рудникка төшмәгән, дөресрәге, төшә алмаган - үлгән булган. Аның биркасына яңа кеше исеме ябыштырыла, аннан тагы яңа кәгазь - шулай дистәләгән кат яңа исемнәр ябыштырылган бирка калыная. Андагы исем вакытлар үтү белән җуелган. Шулай да бер биркада ниндидер сүзләр таныла: "Айзен... Анатолий Петрович. 1931 года рождения. Дата смерти декабрь 1947 года..." Бу мәрхүмгә гомере киселгәндә бары тик 16 яшь кенә була. Биркалардагы җуелган урыннар... Сәбәбе дә, бәлки, лагерьның гайре табигый булуындадыр: мондагы ихтыярый ялланган хезмәткәрләр сак астында - чәнечкеле тимер чыбык белән уратып алынган зонада, ә тоткыннар исә иректә диярлек яшиләр. Ничек болай килеп чыккан соң?! Хикмәт шунда ки, тоткыннар бу урынга китерелгәнче урау юллар үткәннәр. Аларга лагерь идарәсе махсус шундый фикер җиткерә: янәсе, сезнең моннан "Зур җир"гә качу мөмкинлегегез юк, чөнки сезне җәһәннәм түренә - Врангель утравына алып килделәр. Тоткыннар шуңа ышанып яшәгәннәр дә. Арадан бер тоткын шулай да кача алган һәм Көнбатыш илләренең берсенә чыгып, уран рудникгы турында тәфсилләп китап язып бастырган. Китапта сүз Врангель утравы һәм уран рудниклары турында бара.

Чукоткадагы уран рудниклары турындагы мәгълүматлар хәзергәчә ачык килеш кала бирә. Монда аунап яткан, маңгай сөяге тигез итеп киселгән баш сөякләре һаман радиоактив нурланыш чыгарып ята бирәләр...

**Юрий Беликов.**
**("КП").**

("Мәдәни җомга"дан алынды).

*БЕЛМИ КАЛМАГЫЗ, КИЛМИ КАЛМАГЫЗ!*

## ВИТАЛИЙ АГАПОВ - НУРЛАТ СӘХНӘСЕНДӘ.




***Тамашачылар соравы буенча 1 декабрьдә район мәдәният йортында танылган көйләр остасы һәм башкаручы Виталий Агапов һәм аның концерт төркеменең зур чыгышы була. Концертка рәхим итегез!***

***Башлана кичке сәг. 7дә.***
***Билет хакы 20 сум.***

Илһамия Низаметдинова шигырьләре.

## КИЗЛӘҮ

*Минем туган авылым*
*Кизләү диеп атала.*
*Аның яшел үзәннәре*
*Хәтеремдә саклана.*

*Болыннарында - чәчкәләр,*
*Талында - сандугачлар,*
*Ярларында оя кора*
*Чем - кара карлыгачлар.*

*Ишелеп карлар яуганда,*
*Авыл акка күмелә.*
*Үзәне дә, болыны да -*
*Бар да якын күңелгә.*

## ГАФУ ИТӘРСЕҢ МИКӘН?

*Йөрәк сыкрый, җан сызлана,*
*Ниләр кылыйм икән мин?*
*Кирәк икән - киңәшчем дә,*
*Якын дус та булдың син.*

*Кирәк икән - киңәшче дә,*
*Якын дус син һәрчакта.*
*Тәүбә иткән ялгышларым*
*Кабатлана кайчакта.*

*Теләмим дә кабатларга*
*Ялгышларым яңадан...*
*Хата - дорфалыгым өчен*
*Гафу сорыйм аңардан.*

***Кизләү авылы.***

## ГРИПП

# ЛИМОН БЕЛӘН САРЫМСАКТАН КУРКА

Табиблар раславынча, грипп ноябрь азакларында баш калкытачак. Быел ул "өлгереп җитми" калган икән. Шуңа күрә без "иске" A3N2 яки H1N1 грипплары белән чирләячәкбез. Алардан саклану өчен прививка ясатырга кирәк. Бу бигрәк тә балаларга һәм өлкән кешеләргә кагыла.

Гриппка каршы менә мондый бик яхшы рецепт бар: ярты лимонны кабыгы белән ваклап тәлинкәдә кисәсең (согын саклау өчен). Шулай ук уртача зурлыктагы 7 - 8 төш сарымсакны тәлинкәгә куеп ваклыйсың. Боларның барысын да ярты литрлы пыяла савытка тутырасың. Шуның өстенә кайнаган салкын су саласың да, дүрт көнгә караңгы урынга куясың. Аннары аны суыткычка күчерәсең (киселгән лимон белән сарымсакны сыеклыктан чыгармаска).

Бу сыеклыкны көнгә бер тапкыр иртән ашарга утырудан 20 минут элек бер аш кашыгы эчәсең (балаларга бер чәй кашыгы). Даруны язга кадәр эчәргә кирәк. Тәҗрибә күрсәткәнчә, салкын вакытта шушы составны даими рәвештә кабул иткән кеше грипп белән йә бөтенләй авырмаган, йә җиңел формада гына авырган.

Бу состав сарымсак исе бирми, аннан күбрәк лимон исе килә. Шуңа күрә аны эшкә яки мәктәпкә барыр алдыннан да эчәргә мөмкин. Әмма ашказаны - эчәк авырулары - энтероколит, энтерит, гастроэнтероколит, ашказаны һәм юан эчәк шеше булган кешеләргә бу составны файдаланырга ярамый.

**("Заман Татарстан"нан).**



# ШАХМАТ БӘЙРӘМЕ

Шәһәрдә һәм районда үткән спорт ярышлары программасында шахмат тулы хокуклы урын алып тора.

Соңгы елларда бездә квалификацияле шахматчылар сизелерлек артты. Ярышларда эшчеләрне, хезмәткәрләрне, интеллигенция вәкилләрен очратырга була. Шәһәрдә шахмат буенча шәхси - команда беренчелеге ярышлары ачылу 1998нче елның төп вакыйгасына әйләнде. Бәйгедә җиңү өчен 25 спортчы көрәшәчәк.

1998 елның 21 ноябрендә физик хәзерлек буенча балалар - яшүсмерләр клубында шахмат ярышлары башланды. Ике рәт итеп тезелгән шахмат өстәлләре янына беренче шахматчылар җыелды: Р.М.Миннебаев, С.М. Амелин, И.В.Прокопьев, Ә.С.Насыйбуллин һәм шахмат уеннары ветераны В.А.Васяев.

Бәйгедә катнашучылар күтәренке кәефле. Аларга карап катнашучылар арта тора. Кайберәүләр, үзләрен көрәшкә әзерләгәндәй, алдан ук өстәл янына килеп утыралар. Турнирны ачу тантанасы бәйрәмчә булды. Аннары спортчылар бер минут тынлыкта иптәшләре В.В.Чеплаковны искә алдылар. Ул үзенең соңгы көннәренә кадәр "Сельхозтехника" АҖндә эшләде. Шахмат турнирына кагылышлы барлык мәсьәләләрне карап чыкканнан соң көрәш башланды.

Шахмат яратучылар өчен уен көннәрен хәбәр итәм: чәршәмбе - 16.00, шимбә һәм якшәмбе - 10.00 сәгатьләрдә.

Мин, ярышның баш судьясы буларак, барлык катнашучыларга да иҗади уңышлар һәм җиңү телим.

**А.КОСТИН.**

## "ЫШАНЫЧ ТЕЛЕФОНЫ"



25 ноябрьдән Нурлат шәһәр һәм район эчке эшләр бүлегендә теге яки бу сәбәп аркасында кем икәнлекләрен белгертергә теләмәүчеләрдән хәбәрләр алу өчен "ышаныч телефоны" эшли башлый. Бер үк вакытта милициянең эшендә нәтиҗәлелекне күтәрү буенча тәкъдимнәр дә көтәбез.

"Ышаныч телефоны" аша алынган мәгълүматлар җинаятьләрне ачу һәм тикшерү, милиция эшендәге җитешсезлекләр һәм негатив фактларны ачыклауда кулланылачак.



***"Ышаныч телефоны"ның номеры 2-12-30.***

Әлегә ул иртәнге 9дан 11гә кадәр һәм көндезге 3тән 5кә кадәр эшли. Алга таба аның тәүлек буе эшләве дә күздә тотыла, ул хакта аерым хәбәр ителәчәк.

Абонентның кемлеген сер итеп саклау гарантияләнә!

***Эчке эшләр бүлеге штабы.***

## БЕЛДЕРҮЛӘР

***Балалар - яшүсмерләрнең физик хәзерлек клубына (шәһәр стадионында) махсус урта яки югары белемле тренер кирәк.***

ДЮКФП директорына мөрәҗәгать итәргә.

### САТАБЫЗ

**Совет ур., 193 йортта бер бүлмәле фатир (2нче кат).**
Тел.: 5-42-38.

***

**Алып китү өчен чанада 4,5 х 7,5ле, капкасының биеклеге 2,2 метрлы гараж.**
Адрес: Декабристлар ур., 11.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**Үзебезнең илдә чыгарылган йорт җиһазларын өйгә килеп җыеп бирәбез.** Тел.: 5-12-38, кичке 6дан 8гә кадәр.

***

**Нурлат райпосының азык комбинаты халыктан 12 сумнан сыер ите, 13 сумнан дуңгыз ите сатып ала. Түләү ике атна эчендә.** Белешмәләр өчен тел.: 2-16-04, 2-21-15.

Түбән Нурлат урта мәктәбенең IV, V, VII, IX, XI класс укучылары һәм класс җитәкчеләре **әтиләре Тәмаев Әсхать Вазыйх улының** вакытсыз үлүе сәбәпле, аның балаларының, хатыны һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклашалар.

МӨХӘРРИР
**С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19. Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясендә офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2361 данә. 4563